# *Татар теле дәресе.*
# *3 нче сыйныф*

# Максат:

1) Сыйфат темасы белән танышу,аның нинди билгеләр белдерүенә төшенчә бирү.

- 2) Сыйфатларны тексттан таба белү, сыйфатлар кертеп җөмләләр төзү.
- 3) Укучыларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

# Сыйфат

Предметның

**билгесен**

белдерә.

**Нинди? Кайсы?**

сорауларына

җавап бирә.

**Сыйфатлар**

**исемгә**

бәйләнеп

килә.

**Сыйфатлар**

сөйләмне матурлыйлар. Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.

# Сыйфатлар

***<u>төрле билгеләрен</u>*** предметларның белдерәләр:

- **төсне:** *ак, сары, кара, яшел, кызыл;*
- **тәмне:** *ачы, төче, татлы, баллы, тозлы;*
- **форманы:** *озын, түгәрәк, кәкре, кыска;*
- **холыкны:** *көләч, усал, юаш, шаян, сизгер, куркак, кыю, батыр, хәйләкәр, ерткыч;*
- **вакытны:** *кышкы, җәйге, кичке, иртәнге,быелгы;*
- **Табигать күренешләренең билгеләрен:** *буранлы, яңгырлы, җилле, җиләс, аяз, болытлы;*

# *Сыйфатларны  кем табар?*

Ал шар оча.

Яшел шар оча.

Түгәрәк  шар очты.

Миңа  зур шар алдылар.

*Егерме сигезенче февраль.*
*Сыйныф эше.*

*Уу / уу / Уу / уу*

*матур, сылу, алсу йөзле, алтын куллы*

# Физкультминут



**Өзекне чагыштырып укыгыз. Кайсы өзек тулырак, матуррак тоела?**

Тагын яз җитте. Яңгырлар явып үтте. Агачлар яфракларга күмелде. Шомырт чәчәк ата. Өй кыекларында сыерчыклар җилпенә. Һавада тургай сайрый, умарта кортлары, чәчәкләргә чумып, бал җыя.

Тагын кояшлы, ямьле яз җитте. Беренче җылы яңгырлар явып үтте. Агачлар ямь-яшел яфракларга күмелде. Шомырт ак чәчәк ата. Өй кыекларында дәртле сыерчыклар җилпенә, һавада моңлы тургай сайрый, умарта кортлары, хуш исле чәчәкләргә чумып, тәмле бал җыялар.

***Сыйфат сөйләмдә ни өчен кирәк?***

Сыйфатлар сөйләмне матурлыйлар.

Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.

## ***Сыйфатларны кем табар?***

**Көләч, ачык, якты** йөзле,

**Тәмле, йомшак, җылы** сүзле

Әнием – иң **якын** кешем,

Бик остасы һәрбер эшнең.

*(Нажия Саттарова*

# Йомгаклау.

Укучылар, бу дәрес сезгә ошадымы?

Бу дәрестә безниләр эшләдек?

Сыйфат дип нинди сүзләр атала?

Аларга нинди сораулар куела?

Сыйфатлар ни өчен кулланыла?